| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Исполнительный комитет<br>Аксубаевского муниципального района | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Аксубай муниципаль районы<br>башкарма комитеты |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 05 2022 № 136

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе
нигезләмәсен һәм составын раслау турында

Торак-хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне комплексты карау, гражданнарның торакка хокукларын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, торак төзелеше һәм сатып алу өчен социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлекләренә кертелгәндә, торак шартларын яхшыртуга, җәмәгать контролен һәм коррупцион хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән федераль һәм региональ программаларны (чараларны) гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта).
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Бердәм иҗтимагый торак комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 19.01.2006 ел, № 2, 10.04.2008 ел, № 38 карарлары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
«23»__05___ 2022, № 136
карары белән расланган
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба – Комиссия) җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә Аксубай муниципаль районында яшәүчеләрнең торак хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне объектив, һәрьяклап карау максатыннан оештырылган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Торак комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм хокукый актлары, муниципаль хокукый актлармуниципаль хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия составы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

1.4. Әлеге Нигезләмә Комиссиянең вәкаләтләрен һәм ул хәл итә торган мәсьәләләр даирәсен билгели.

## 2. Иҗтимагый торак комиссиясен төзү һәм бетерү тәртибе

2.1. Татарстан Республика Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Комиссияне төзү һәм бетерү турында карар рәвешендә карар кабул итә, шулай ук аның шәхси составын раслый.

2.2. Комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

2.3. Иҗтимагый торак комиссиясе составына җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, хезмәт коллективлары, профсоюзлар, ветераннар,

яшьләр һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала, шулай ук граждан җәмгыяте институтлары вәкилләрен кертү рөхсәт ителә.

2.4. Комиссия составында кворум өчен әгъзаларның саны, әмма иҗтимагый торак комиссиясе составының кимендә 2/3 составы булырга тиеш.

2.5. Комиссия составы 9 кешедән тора.

## 3. Иҗтимагый торак комиссиясенең төп бурычлары, функцияләре һәм хокуклары

3.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү мәсьәләләрендә җәмәгать контролен һәм хәбәрдарлыкны тәэмин итү;

-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән торак законнары нигезендә гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

3.2. Комиссия компетенциясенә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан тапшырыла торган гаризаларны һәм документларны түбәндәге мәсьәләләр буенча карау керә:

- гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аз керемлеләр дип тану;

- гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу;

- гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;

- социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнарга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына бирелә торган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак төзү яки сатып алу өчен социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлеген килештерү;»;

- Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую, яңадан теркәү һәм исәпкә алу эшләренә үзгәрешләр кертү;

- «Авылны социаль үстерү», «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү», «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программалары шартларын үтәү турындагы мәсьәләләрне карау, документларны алга таба Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына җибәрү өчен;

- федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән аерым категорияләрдәге гражданнарның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую;

- гражданнарны федераль льготниклар исемлегеннән төшереп калдыру;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль торак фондыннан наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирү;

- «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү һәм исәпкә кую.

3.3. Комиссия хокуклы:

- утырышларда аның компетенциясенә караган мәсьәләләрне карау;

- билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты, Дәүләт хакимияте органнарыннан, учреждение һәм оешмалардан комиссия эше өчен кирәкле документларны, мәгълүматны, белешмә материалларны соратып алырга;

- гражданнар тарафыннан тапшырыла торган документлардагы белешмәләрне тикшерү өчен эшче төркемнәре булдырырга ;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

- Комиссия бурычларыннан һәм вәкаләтләреннән килеп чыга торган башка гамәлләрне гамәлгә ашыру.

## 4. Комиссиясенең эш тәртибе

4.1. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы була. Комиссия утырышын үткәрү турындагы карар Комиссия рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан кабул ителә. Кирәк булган очракта, Комиссия утырышына кызыксынучы затлар чакырылырга мөмкин.

4.2. Комиссия Рәисе:

- Комиссия эшенә гомуми җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра;

- Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итә;

- Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен персональ җаваплылык тота.

4.3. Комиссия Секретаре:

- Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә материалларны тикшерү һәм карауны оештыра;

- Комиссия утырышында каралырга тиешле мәсьәләләрне әзерли;

- Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

- Комиссия карарлары проектларын әзерли.

- Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча барлык документлар комиссия секретарендә саклана.

4.4. Комиссия әгъзалары хокуклы:

көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча Комиссия утырышларында чыгыш ясарга;

кабул ителгән Комиссия белән килешмәгән очракта, комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри кушылырга тиешле аерым фикерне язмача белдерергә.

4.5. Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән комиссия әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән карар кабул итә. Тавыш биргәндә Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия.

4.6. Комиссия әгъзасы, кабул ителгән карар белән килешмичә, үзенең аерым фикерен язмача бәян итә һәм аны Комиссия утырышы беркетмәсенә куя ала.
4.7. Утырышның көн тәртибе комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән раслана.
4.8. Комиссия утырышы кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.
4.9. Әгәр комиссия әгъзасы нинди дә булса сәбәпләр аркасында утырышта катнаша алмаса (отпуск, авыру, командировкадан тыш), ул телефон элемтәсе аша бу хакта комиссия секретаренә хәбәр итәргә тиеш.
4.10. Комиссия утырышында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла. Беркетмәдә комиссия исеме, утырыш датасы, беркетмә номеры, утырышта катнашучылар саны һәм исемлеге, көн тәртибе чагылдырылырга тиеш.
Беркетмәгә карала торган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге кертелә, алар буенча кабул ителгән карар, кирәк булганда, конкрет мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларының аерым фикере кертелә.
Беркетмәгә комиссия рәисе һәм секретаре кул куя. Комиссия беркетмәләре архив эше турындагы законнар нигезендә саклана.
Комиссия карары тәкъдим итү характерына ия.

## 5. Комиссиясенең җаваплылыгы

Комиссия әгъзалары комиссия утырышында кабул ителгән карарларның нигезләмә шартларына туры килү/килмәве өчен җитди җаваплылык тоталар.
Комиссия әгъзалары җыелма исемлекләрне формалаштыру, исәп эшләрен алып бару һәм гамәлдәге законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен гаиләләрнең локаль исемлекләрен тоту өчен җаваплы.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
«23» 05 2022, № 136
карары белән расланган
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составы

Комиссия рәисе-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

Комиссия рәисе урынбасары-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Комиссия секретаре-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге белгече.

Комиссия әгъзалары:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы;
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай ш. т. п. Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Аксубай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);
«ТР БТИ» АҖнең Нурлат филиалы Аксубай бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча);
«ТР Президенты каршындагы ДТФ» ның Әлмәт төбәкара вәкиллеге җитәкчесе (килешү буенча);
Россия ЭЭМның Аксубай районы буенча бүлегенең икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы тору буенча оператив вәкиле (килешү буенча).